РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
КРЯШ-ШУРАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

423978, Р.Т. Муслюмовский район, с. Кряш-Шуран, улЦентральная 6а,
Kshur.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-35-45
ИНН 1629001057, КПП 162901001, ОГРН 1021605558732, ОКАТО 92242825000,
ОКТМО 92642425

Керэш-Шуран авылы « 21 » март 2019 ел

# КАРАР № 2

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл жирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 7 маддәсе нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хужалык һәм торак объектларын, юлларны һәм күперләрне саклауны кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл жирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Керэш-Шуран авыл жирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия төзү.
2. Керэш-Шуран авыл жирлеге территориясендә 4 кешедән торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзергә һәм 2019 елгы язгы ташу чорында Керэш-Шуран авыл жирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын расларга.
3. Керэш-Шуран авыл жирлеге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерүне һәм икътисад объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә тәкъдим итәргә:
   - Керэш-Шуран авыл жирлегенен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгы, язгы ташуга каршы комиссия утырышларында икътисад объектларының куркынычсызлыгы, язгы ташу суларының авариясез үтүен тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
   - язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә игътибар бирү һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә жәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын ачыклау. Көч һәм чаралар турында мәгълүматлар жыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен тикшереп тору;
   - елга һәм буаларда, саркофагларсыз үләт базлары янында су дәрәжәсен тәүлек буе күзәтү өчен вакытлыча постлар оештырырга; - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
   - язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка житкерүне тәэмин итәргә;
   - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтижәләреннән саклау буенча чараларның үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Керэш-Шуран авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты житәкчесе** **Сафиуллин Р.Г.**

Мөслим муниципаль районы
Керэш-Шуран авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«21» март, 2019 ел,
2нче санлы Карарына
1нче кушымта

**Керэш-Шуран авыл җирлеге буенча**
**гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне тәэмин итү комиссиясе**

1. Сафиуллин Р.Г.
2. Софина Г.К.
3.Шаева В.М..
4.Галимова Л.Р.,
5. Ахметов З.Г.
6.Нарожник Г.М.
7.Ильина Е.В.

**Керэш-Шуран авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Сафиуллин Р.Г.**